КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 февраль г.Казань № 83

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2023 елның 30 декабрендәге 920 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы тора дип билгеләргә.
3. Казан шәһәре контракты буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пунктына һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына Тәртипкә нигезләнеп эш итүне тәкъдим итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 15 февраль, 83 нче
карары белән расланды

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә
бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Әлеге Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы территориясеннән өлешчә мобилизация буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләр, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Татарстан Республикасында урнашкан хәрби частьләрендә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби частьләрендә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты яки Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты тарафыннан эш нәтиҗәләре буенча әлеге контракт төзү турында карар кабул иткән хәрби хезмәткәрләр арасыннан 2023 елның 31 декабреннән соң Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) механизмын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты тарафыннан әлеге Тәртипнең 1 – 3 нче кушымталарында бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) җибәрелә торган исемлекләр (алга таба – исемлекләр) нигезендә 305,0 мең сум күләмендә бирелә.

3. Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә Министрлыкка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

4. Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 9 статьясы нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнардан аларның шәхси белешмәләрен Министрлык тарафыннан эшкәртүгә һәм Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пунктына башкарылган түләүләр турында белешмәләр тапшыруга ризалык алуны тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, Министрлык, Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның алынган шәхси мәгълүматлары конфиденциальлеген һәм сакланышын тәэмин итә, аларны хокуксыз файдаланган өчен федераль закон нигезендә җавап бирә.

6. Әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү суммаларын күчерү Министрлык тарафыннан Министрлыкка түләүгә акча кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә башкарыла.

7. Министрлык хисап елынннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»
Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты башлыгы

__________ ____________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» ___________

«Килештерелде»
Татарстан Республикасы Хәрби комиссары

__________ ____________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» ___________

Татарстан Республикасы территориясеннән өлешчә мобилизация буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган, 2023 елның 31 декабреннән соң Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Кредит оешмасының исеме | Кредит оешмасының ИНН/КППы | Кредит оешмасының БИКы | Кредит оешмасындагы шәхси счет номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Башкаручы _________________ ______________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»
Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты башлыгы

__________ ___________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» ___________

«Килештерелде»
Татарстан Республикасы Хәрби комиссары

__________ ___________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» ___________

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Татарстан Республикасында урнашкан хәрби частьләрендә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы, 2023 елның 31 декабреннән соң Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр
исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Кредит оешмасының исеме | Кредит оешмасының ИНН/КППы | Кредит оешмасының БИКы | Кредит оешмасындагы шәхси счет номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Башкаручы __________________ ________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»
Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты башлыгы

_________ _______________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» __________

«Килештерелде»
Татарстан Республикасы Хәрби комиссары

_________ _______________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «___» __________

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби частьләрендә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, 2023 елның 31 декабреннән соң Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты яки Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты тарафыннан эш нәтиҗәләре буенча әлеге контракт төзү турында карар кабул иткән хәрби хезмәткәрләр
исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Кредит оешмасының исеме | Кредит оешмасының ИНН/КППы | Кредит оешмасының БИКы | Кредит оешмасындагы шәхси счет номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Башкаручы _______________ _________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

_________________________